СОВЕТ
НОВОБУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Вокзальная, дом 31,
П.ж.-д.ст.Бурундуки, Дрожжановский район 422490

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА БОРЫНДЫК
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Вокзал урамы, 31 нче йорт,
Борындык тимер юл ст. поселогы,
Чүпрәле районы
422490

Тел.: (84375) 3-17-45, 3-17-03, факс: (84375) 3-17-45, e-mail: Nbur.Drz@tatar.ru,
www. Nbur -drogganoe.tatarstan.ru

# КАРАР

2020 нче елның 13 ноябрь                                                  № 3/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлегенең 2020 елның 27 февралендәге 81/2 номерлы карары (08.06.2020 редакциясендә) белән расланган Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**11 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«5. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында аларның тиешле вазыйфасын биләгән чорында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.»;

**15 статьяның 1 пунктындагы 5 пунктчасына** түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә: «Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмаганда башкарыла. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү турында мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә җайга салынганда тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү мондый билгеләнеш өчен мөрәҗәгать иткән көннән алып башкарыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Борындык авыл җирлеге башлыгы: В.Г. Ранцев